Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.12.2025 Менделеевск ш. № 774

Югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге
нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен
мониторинглау һәм башлангыч
белешмәләрне җыю өчен җаваплы
затларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2024 елның 28 ноябрендәге 1014 номерлы Указын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Рәисенең муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен мониторинглау һәм башлангыч белешмәләрне җыю өчен җаваплы вазыйфаи зат итеп Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад, алгарышлы социаль икътисади үсеш территориясен һәм эшкуарлыкны үстерү буенча урынбасары - Гәрәева Лилия Әнвәр кызын билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Рәисенең муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен мониторинглау һәм башлангыч белешмәләрне җыю өчен җаваплы белгеч итеп Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад, сәнәгать һәм эшкуарлыкка ярдәм итү бүлеге башлыгы-Сперанова Светлана Евгеньевнаны билгеләргә.
3. Менделеевск муниципаль районы Советы Аппаратының кадрлар эше буенча сектор мөдиренә:
3.1. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад, алгарышлы социаль икътисади үсеш территориясен һәм эшкуарлыкны үстерү буенча урынбасарының вазыйфаи инструкциясенә Татарстан Республикасы Рәисенең муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен мониторинглау һәм башлангыч белешмәләрне җыю эшчәнлеген оештыру бүлеген кертүне тәэмин итәргә.

3.2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад, сәнәгать һәм эшкуарлыкка ярдәм бүлеге башлыгының вазыйфаи инструкциясенә Татарстан Республикасы Рәисенең муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен мониторинглау һәм башлангыч белешмәләрне җыю өчен бурычларны, хокукларны һәм җаваплылыкны йөкләү бүлеген кертүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Менделеевск муниципаль районының мәгълүмат сайтында урнаштырырга (https://mendeleevsk.tatarstan.ru)

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Ф.Искаков